**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7761**
**25.08.2023**

Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8501 номерлы карары белән расланган җир участокларын милеккә бушлай бирү хокукына ия затлар буларак, гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32.1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 25 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге 76-ТРЗ номерлы Законы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8501 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 25 апрелендәге 3370 номерлы карары редакциясендә) расланган җир участокларын милеккә бушлай бирү хокукына ия затлар буларак, гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.2 пунктның беренче абзацына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«әгәр мондый гражданнар җир участогы бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәсәләр һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә торсалар. Әгәр дә ата-аналарның берсе яки бердәнбер ата яки ана җир участогы бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәсә, өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар җир участогы бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү турындагы таләпкә туры килә дип санала.»;

2) 2.4.1 пунктның икенче абзацында «аларны индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен җир участогы алу хокукына ия гражданнар исемлегенә керткән датадан башлап бер елдан соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 2.5.1 пунктта өстәргә:

- түбәндәге эчтәлектәге 9 һәм 10 пунктчалар:

«9) гариза бирүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ буларак исәптә торуын раслаучы документ;

10) гариза бирүченең җир участогы бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карары (гариза бирүченең паспортында җир участогы бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында аның Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлүе турында билге булмаган очракта);».

- түбәндәге эчтәлектәге абзац:

«Әгәр гариза бирүче аны үз инициативасы буенча тапшырмаса, әлеге пунктның 9 пунктчасында күрсәтелгән документ җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә сорала.».

4) 2.8.2.пунктта:

- 2 пунктчага түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптән төшерелү.»;

- 4 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) гражданнарның җир участогын сайлау процедурасында җир участогын сайлаудан өч тапкыр баш тартуы, яисә гражданнарның җир участогын сайлау процедурасына өч тапкыр килмәве, яисә гражданнарның җир участогын сайлау процедурасында җир участогын сайлаудан баш тарту һәм җир участогын сайлау процедурасына килмәү очракларының саны барысы бергә өчкә тигез булганда;»;

5) 3.6.3.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Гражданнарга аларны исемлеккә кертүдән баш тарту турында хәбәр итү җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән башлап җиде көннән дә соңга калмыйча, тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат яисә аларга хәбәрне имза куйдырып тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов